ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ӘТНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕАТНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422750 Республика Татарстан Атнинский район с. Б.Атня Тел. 2-15-68

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«17» август 2022 ел

**КАРАР**
№ 21

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фондыннан акча тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезендә һәм көтелмәгән чыгымнарны, шул исәптән авария-торгызу эшләрен һәм табигый бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле башка чараларны үткәрүгә, шулай ук башка чараларга финанс ягыннан тәэмин итү максатларында карар бирәм:

1. Расларга:
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фондыннан акча тоту тәртибе турындагы нигезләмәне (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау буенча комиссия составы (2 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фондыннан бирелгән акчалардан максатчан файдалану турында хисап формасын (3 нче кушымта).
2. Әлеге карарны, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http//pravo.tatarstan.ru., Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http//atnya.tatar.ru бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Олы Әтнә авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Л.А.Самигуллин

:

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма
комитетының 2022 нче елның
17 августындагы 21 нчы номерлы карарына
1 нче кушымта

Нигезләмә

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты резерв фондыннан акча тоту тәртибе турында

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фонды, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезендә, тиешле елга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге бюджетында каралмаган җирле әһәмияттәге чараларны һәм көтелмәгән чыгымнарны финанслау өчен төзелә.

2. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фондыннан акча бүлеп бирү һәм алардан файдалану тәртибен билгели.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетының Резерв фонды күләме Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең бюджеты турында»гы карары белән билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фонды акчалары көтелмәгән чыгымнары финанс яктан тәэмин итүгә юнәлдерелә, шул исәптән:

– табигый бәла-казалар, янгыннар һ. б. гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү белән бәйле авария-торгызу эшләрен һәм башка чаралар үткәрү, һәм аларны кисәтү;

- гадәттән тыш хәлләрне булдырмау максатыннан кичектергесез эшләр үткәрү;

- Гражданнар оборонасы, табигатьне саклау буенча чаралар үткәрү,
эпидемиягә каршы җирле әһәмияттәге чаралар;

- социаль – мәдәни өлкә, физик культура һәм спорт үсешенә ярдәм итү;

- җирле әһәмияттәге юбилей, дини һәм башка төрле чаралар үткәрү;

- җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларга социаль ярдәм чаралары, шул исәптән дәүләтчелекне, җирле үзидарә, икътисад, сәнәгать, авыл хуҗалыгы, фән, мәдәният, сәнгать, мәгариф, сәламәтлек саклау, спорт, законлылыкны, хокук тәртибен тәэмин итү, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклау һәм башка казанышлар (казанышлар);

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге бюджетында каралмаган башка чаралар һәм чыгымнар.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фондыннан акчаларны көтелмәгән чыгымнарны һәм җирле әһәмияттәге чараларны финанслауга бүлеп бирү әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгәнчә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетына, җирле үзидарә органнарына, физик һәм юридик затлар мөрәҗәгате нигезендә гамәлгә ашырыла.

Физик һәм юридик затлар, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгать белән бергә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетына билгеләнгән максатларга чыгымнарның кирәклеген, кичектергесез һәм көтелмәгән булуын раслый торган документлар (шул исәптән китерелгән зыян турында органнар белешмәләре йә кирәкле күләмне нигезли торган, смета финанс исәп-хисап, калькуляция, чыгымнар, счет фактура һәм проект – смета документациясе) да кертеп тапшыралар

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фондыннан акча алу шарты булып, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр түләү буенча бурычлар (үтәлмәгән бурыч) булмау тора

6. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты 3 көн эчендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне һәм чыгымнарның кирәклеген, кичектергесез булуын һәм көтелмәгәнлеген раслаучы документларны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фондыннан акча бүлеп бирү турында мөрәҗәгатьне карау буенча комиссиягә җибәрә, (алга таба-комиссия), түбәндәге мәсьәләләрне чишү өчен:

- резерв фондыннан акча бүлеп бирү зарурлыгы яки зарурлыгы булмау турында;

- бүлеп бирелә торган акча күләмен билгеләү турында.

7. Комиссия составы Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән раслана.

8. Комиссия рәисе комиссияне җитәкли һәм аның эшен оештыра.

9. Комиссия утырышы аның составының кимендә өчтән ике өлеше булганда тулы хокуклы.

10. Комиссия утырышы Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетыннан кергән мөрәҗәгатьләр һәм документлар белән бәйле рәвештә үткәрелә.

Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Комиссия карарлары катнашучыларның гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булган очракта, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора. Утырыш беркетмәсенә һәм кабул ителгән карарга комиссия рәисе кул куя.

Утырышта катнаша алмаган очракта, комиссия әгъзасы каралучы мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул утырышта игълан ителә һәм беркетмәгә теркәлә.

Кабул ителгән карар белән килешмичә, комиссия әгъзасы язма рәвештә үзенең аерым фикерен бәян итәргә хокуклы, ул утырыш беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә кушылырга тиеш.

11. Комиссия 7 эш көне дәвамында карар чыгара. Комиссия карары тәкъдим итү характерына ия. Комиссиянең кабул ителгән карары 2 көн эчендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетына җибәрелә.

12. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фондыннан акча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты күрсәтмәсе нигезендә бүлеп бирелә.

13. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Башкарма комитетының Резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы күрсәтмәләре Әтнә муниципаль районы Башкарма – боеру органнары һәм оешмалары карамагында булган акчалар җитәрлек булмаган очракларда кабул ителә. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Башкарма комитетының Резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы күрсәтмәсенә ассигнованиеләрнең гомуми күләме һәм аларны алучыларга һәм үткәрелә торган чаралар буенча бүленеше күрсәтелә. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты күрсәтмәләрендә каралмаган максатларга акча куллану рөхсәт ителми.

14. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан бүлеп бирелә торган акча күләмен һәм аларны сарыф итү юнәлешен күрсәтеп, резерв фондыннан акча бүлеп бирү турында күрсәтмәләр проектларын, комиссия беркетмәсе алганнан соң 3 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты әзерли.

15. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фондыннан акча авария-торгызу эшләрен башкару һәм башка чаралар үткәрү, табигый бәла-казалар, янгыннар, башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле торгызу эшләрен үткәрү һәм аларны кисәтү, шулай ук Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге бюджетында каралмаган гадәттән тыш хәлләрне булдырмау максатыннан кичектергесез эшләр башкаруга (бары тик җирле дәрәҗәдәге чараларны һәм эшләрне финанслауга гына) бүлеп бирелә.

16. Резерв фондыннан акча түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә бирелә. Резерв фондыннан акча максатчан характерда була һәм башка максатларда файдаланыла алмый.

17. Җирле үзидарә органнары, резерв фонды акчалары бүлеп бирелә торган физик һәм юридик затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә акчаларны максатчан файдаланмаган өчен җаваплы һәм тиешле чаралар үткәргәннән соң бер ай эчендәТатарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты резерв фондыннан бирелгән акчалардан максатчан файдалану турында хисап тапшыралар, раслый торган документлар белән.

18. Төзелгән килешүләр нигезендә, «Әтнә муниципаль районы Контроль – хисап палатасы» резерв фонды акчаларының максатчан файдаланышын контрольдә тота.

19. Бүлеп бирелгән акчалар үзләштерелмәгән, алучы тарафыннан бирелгән акчалардан максатчан файдалануны бозу очраклары ачыкланган, дөрес булмаган белешмәләр булган документларны тапшырган очракта Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

20. Акча бирүне туктату һәм (яки) кире кайтару турындагы карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты кабул итә.

21. Акчаларны кире кайтару Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Башкарма комитетының язмача таләбе буенча, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Башкарма комитетының, Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының Казначылык Департаментының территориаль бүлегендә ачык шәхси счетына күчерү юлы белән бәхәссез рәвештә башкарыла.

22. Акчаларны ирекле кире кайтарудан баш тарткан очракта алар Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма
комитетының 2022 нче елның
17 августындагы 21 нчы номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе | |
| САмигуллин Ленар Адгамович | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| Комиссия секретаре | |
| Маликова Резеда Радиновна | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы урынбасары |
| Комиссия әгъзалары | |
| Мухаметгалиева Равиля Ракиповна | 3нче номерлы сайлау округы буенча Олы Әтнә авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча) |
| Галяутдинов Реваль Равилович | 7 нче номерлы сайлау округы буенча Олы Әтнә авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча) |
| Гарипов Рафиль Рафаэлович | 10нче номерлы  сайлау округы буенча Олы Әтнә авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча) |
| Зайнуллин ЛЕнар Ильфирович | 9нче номерлы  сайлау округы буенча Олы Әтнә авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма
комитетының 2022 нче елның
17 августындагы 21 нчы номерлы карарына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге
Башкарма комитетының резерв фондыннан
бирелгән акчалардан максатчан файдалану турында хисап

Алучының исеме
______________________________________________________________________

Салым түләүченең идентификацион номеры (ИНН)
______________________________________________________________________

Үлчәү берәмлеге: сум.

______________________________________________________________________
__________________________

| Чыгымнар юнәлешләре (сум) | Бирелгән акча (сум) | Фактта финансланган (сум) | Кулланылмаган акча калдыгы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |
| | | | | |

Җитәкче ____________ ______________ баш хисапчы ____________ _________________
(имза) (расшифровка) (имза) (расшифровка)

«______» ___________________20 __ ел

ПУ